ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында “сатудан” сүзеннән соң “, кыйммәтле металларның һәм кыйммәтле ташларның дәүләт запасларын реализацияләүдән” сүзләрен өстәргә;

2) 25 статьяның 1 пунктындагы унынчы абзацында “сатудан” сүзеннән соң “, кыйммәтле металларның һәм кыйммәтле ташларның дәүләт запасларын реализацияләүдән сатып алу бәясе күләменә киметелгән” сүзләрен өстәргә;

3) 29 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Татарстан Республикасының эчке дәүләт хисаплашулары һәм муниципаль хисаплашулар Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет кытлыгын финанслау максатларында, шулай ук Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен каплау, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет счетларында калган акчаларны тулыландыру өчен тиешенчә финанс елы дәвамында гамәлгә ашырыла.”;

4) 41 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Һөнәри керемгә салымнан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салым керемнәре шәһәр, авыл җирлекләренең һәм шәһәр округларының бюджетларына 100 процент норматив буенча күчерелә.”;

5) $47^2$ статьяда:

а) “Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүченең” сүзләрен “1. Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүченең” сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

“2. Судта Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен тәкъдим иткән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә квартал саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Граждан кодексының $108^1$ статьясындагы $3^1$ пункт нигезендә Татарстан Республикасы тарафыннан регресс хокукын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән гамәлләр турында йә регресс тәртибендә акчалата түләтү хакында дәгъва бирү өчен нигезләрнең булмавы турында мәгълүмат бирә.”;

а) 49 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа утыз өченче абзац өстәргә:

“Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда каралган очракларда судларда Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен тәкъдим итә;”;

б) утыз өченче – кырык бишенче абзацларны тиешенчә утыз дүртенче – кырык алтынчы абзацлар дип санарга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, 1 статьясының 4 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 19 декабрь
№ 102-ТРЗ